КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 август г.Казань № 687

Буа муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге башкарма комитетының Буа муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 5,621 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:14:100201:175 кадастр саны белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин